ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

1 статья

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) унөченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда эш иткән, әгәр шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга җәлеп ителүче янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составы, янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, янгын сүндерүдә башка катнашучылар матди зыян китергән өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлекле унбишенче өлеш өстәргә:

«Акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда эш иткән, әгәр шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга җәлеп ителүче янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составы, янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, янгын сүндерүдә башка катнашучылар коткарылучы кешеләрнең, янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составының, янгын сүндерүдә башка катнашучыларның сәламәтлегенә зыян китергән яисә аларның һәлак булуы өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 13-ТРЗ